КАРАР

25 ноябрь, 2023 ел № 1

Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге Янил авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 25 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Янил авыл җирлеге Янил авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокլы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Янил авылындагы юлларга вак таш җәю һәм ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

2) Янил авылында урам юл челтәрен карап тоту, юл билгеләре сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

3) Янил авылына энергия саклаучы лампалар, светодиодлы яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау; Янил авылында урам яктыртуны карап тоту, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

4) йорт төзү, урнаштыру, ремонтлау, Янил авылында күпләп ял итү урыннарын һәм аларга якын территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

5) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү, янгын гидрантларын, янгын сүндерү савытлары һәм кирәкле җиһазлар, инвентарь сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

6) Янил авылының Үзәк урамында су белән тәэмин итү системалары төзү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

7) җәяүлеләр кичүен һәм тротуарны ремонтлау, төзү һәм карап тоту, тротуар өчен бордюрлар сатып алу, урнаштыру һәм алар тирәсендәге территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

8) массакүләм ял итү урыннарын чүп-чар урналары белән җиһазлау?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 452 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 231 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 222 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 9 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Янил авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Янил авыл җирлеге Янил авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Янил авылындагы юлларга вак таш җәю һәм ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

2) Янил авылында урам юл челтәрен карап тоту, юл билгеләре сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

3) Янил авылына энергия саклаучы лампалар, светодиодлы яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау; Янил авылында урам яктыртуны карап тоту, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

4) йорт төзү, урнаштыру, ремонтлау, Янил авылында күпләп ял итү урыннарын һәм аларга якын территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

5) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү, янгын гидрантларын, янгын сүндерү савытлары һәм кирәкле җиһазлар, инвентарь сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

6) Янил авылының Үзәк урамында су белән тәэмин итү системалары төзү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

7) җәяүлеләр кичүен һәм тротуарны ремонтлау, төзү һәм карап тоту, тротуар өчен бордюрлар сатып алу, урнаштыру һәм алар тирәсендәге территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

8) массакүләм ял итү урыннарын чүп-чар урналары белән җиһазлау?

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,

Янил авыл җирлеге башлыгы: И.Х. Корбанов